ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

02.09.2026 п.г.т.Алексеевское № 549-р

**«2026 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 29.01.2026 № 45-р Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучы балаларны түләүсез кайнар азык белән туклану белән тәэмин итүгә 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча бер укучыга кайнар азык белән туклануның уртача бәясен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары, «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучы балаларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6 өлеше, «Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә (үзгәрешләр белән 14.11.2022 № 1213) «2026 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны тукландыруны оештыру турында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.01.2026, ел № 45-р күрсәтмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.7 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга, өйдә белем алучы инвалид балаларга ике тапкыр түләүсез туклануны, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучыга, инвалид балага акчалата компенсация белән алмаштыру турындагы гариза нигезендә уку көннәре өчен акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеген карарга».

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ җитәкчесенә үзгәрешләр нигезендә укучыларны кайнар азык белән тукландыруны оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчан файдаланылуын тикшереп торырга (Крохина Н.А.).

3. Әлеге күрсәтмә имза салынган вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**